**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КҮГЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**2020 елның 04 сентябре** **№253**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең бюджет процессын оештыру һәм җирлекнең бюджет һәм автоном учреждениеләренең шәхси счетларын ачу һәм алып бару буенча аерым вәкаләтләрен тапшыру турында.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 һәм 15 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының "Күгеш авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Күгеш авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә бюджет процессын оештыру һәм җирлекнең бюджет һәм автоном учреждениеләренең шәхси счетларын ачу һәм алып бару буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Күгеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгеш авыл җирлеге җирле үзидарә органы белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең үз матди ресурслары һәм финанс чаралары хисабына гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Күгеш авылы, Мәктәп яны урамы, 1 нче йорт (администрация бинасы), Күгеш авылы, Советская урамы, 17 нче йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Күгеш авыл җирлеге башлыгына йөкләнә.

**Күгеш авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **А.А.Гатауллин**